КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 гыйнвар г.Казань № 11

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру хакында» 2013 ел, 29 июнь, 449 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру хакында» 2013 ел, 29 июнь, 449 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт фонды акчасын күпфатирлы йортны сүтү яки реконструкцияләү максатларына файдалану тәртибенең 6 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Бу күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яки) башкарылган эшләр һәм сүтү максаты өчен сарыф ителгән акчаны тотып калып, капиталь ремонт фонды акчасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан мондый йортны авария хәлендәге йорт дип тану турындагы карар билгеләгән тәртиптә кабул ителгәнгә кадәр махсус исәп хуҗасы һәм (яки) төбәк операторы тарафыннан бу күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләре арасында капиталь ремонт өчен алар тарафыннан түләнгән кертемнәр һәм тиешле

урыннарның элеккеге милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен түләнгән кертемнәр күләменә пропорциональ рәвештә бүленә.»;

әлеге карар белән расланган Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт фонды акчасын түләү тәртибенең 4 нче пункттагы икенче абзац үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин